РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.07.2020 Буа шәһәре № 275 ик-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау турында карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 70.1 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау турындагы Нигезләмә», Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Буа шәһәр Советының 2009 елның 22 декабрендәге 2-37 номерлы карары белән расланган, Буа муниципаль районының Буа шәһәре Генераль планы нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 февралендәге 46/ИК-п номерлы «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау турында»гы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.1пункт.:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак, җитештерү, мәдәни-көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар, җир кишәрлегенең максатчан билгеләнеше һәм шәһәр төзелеше регламентлары, төзелеш, экологик, санитар-гигиена, янгынга каршы һәм башка кагыйдәләр, нормативлар таләпләрен үтәп, аларны куллану рөхсәтенә туры китереп, торгызырга;»;

13 абзацта «наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары» сүзләрне төшереп калдырырга;

15 абзацны төшереп калдырырга;

16, 17 абзацларны 15, 16 абзацлар дип санарга;

пунктның 16 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча бертуганнары һәм (яисә) апалары укый торган Буа муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларына укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия.».

«кызыксынган затларны резервланучы җирләр схемасы белән таныштыру урыны һәм вакыты турында, шулай ук резервланучы җирләр чикләрендә тулысынча яисә өлешчә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлеге турында белешмәләр.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Камартдинов